Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 3 ноябреннән Менделеевск ш. №9

Менделеевск муниципаль районы Советының
«Менделеевск муниципаль районы
җирле үзидарә органнары структурасын раслау турында»
2015 елның 27 октябрендәге
18 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы белән, һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының бер штат берәмлеген Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетына күчерергә һәм аны штат берәмлегенә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасары дип үзгәртергә.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы структурасында:

2.1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының гомуми бүлегенең әйдәүче белгече вазыйфасын Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының гомуми бүлеге баш белгече вазыйфасына үзгәртергә.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетында:

3.1 Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы, торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше буенча беренче урынбасары вазыйфасын Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары итеп үзгәртергә;

3.2 Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең стратегик үсеш буенча урынбасары вазыйфасын

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад, ТОСЭР һәм эшкуарлыкны үстерү буенча урынбасары вазыйфасына үзгәртергә;

3.3 Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте, шәһәр хуҗалыгы һәм сәүдә бүлеге баш белгече вазифасын торак сәясәте, шәһәр хуҗалыгы һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының сәүдә бүлеге башлыгы урынбасары вазыйфасына үзгәртергә.

4. Әлеге карар 2020 елның 1 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Совет Рәисе В.С.Чершинцев